МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

14.11.2018 г. Казань № 3817-р

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2014 ел, 24 ноябрь, 2572-р карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектларының (җир кишәрлекләреннән тыш) дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләренә үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында” 1998 ел, 29 июль, 135-ФЗ Федераль законының 24.18 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе каршындагы кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләре турында бәхәсләрне карау буенча комиссиянең 2018 елның 7 сентябрендәге № 241, 242, 243, 2018 елның 28 сентябрендәге № 260 карарлары нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектларының (җир кишәрлекләреннән тыш) дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2014 ел, 24 ноябрь, 2572-р карары белән расланган, 2014 елның 1 январе торышындагы, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектларының (җир кишәрлекләреннән тыш) дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләренә (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 ел,

13 февраль, 279-р, 2017 ел, 21 апрель, 894-р, 2017 ел, 23 июнь, 1388-р, 2017 ел, 22 август, 1923-р, 2017 ел, 26 сентябрь, № 2174-р, 2018 ел, 15 февраль, № 366-р, 2018 ел, 8 июнь, № 1588-р, 2018 ел, 6 август, № 2301-р, 2018 ел, 25 сентябрь, № 3152-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) ышанычлы булмау аркасында, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«Күчемсез милек объектларының кадастр бәясе» бүлегендә:

«Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге» бүлекчәсендә:

188510 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «188510 | 16:52:040103:5877 | 130115,49»; |

188515 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «188515 | 16:52:040103:5881 | 129176,03»; |

188520 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «188520 | 16:52:040103:5886 | 128236,56»; |

18523 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «188523 | 16:52:040103:5889 | 128706,29»; |

2. «Дәүләт теркәү, кадастр һәм картография федераль хезмәте федераль кадастр палатасы» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына күчемсез милек объектларының кадастр бәясе үзгәрүе турында тиешле тәртиптә белешмә кертергә тәкъдим итергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru адресындагы рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Р.Мерзакреевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**